КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 декабрь г.Казань № 1086

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 11 ноябрь, 866 нчы, 2014 ел, 8 май, 304 нче, 2014 ел, 17 май, 330 нчы, 2014 ел, 26 декабрь, 1032 нче, 2016 ел, 17 февраль, 98 нче, 2017 ел, 30 сентябрь, 733 нче, 2018 ел, 20 март, 159 нчы, 2019 ел, 8 апрель, 274 нче, 2019 ел, 21 май, 427 нче, 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы, 2019 ел, 31 октябрь, 985 нче, 2019 ел, 24 декабрь, 1186 нчы, 2020 ел, 25 февраль, 140 нчы, 2020 ел, 1 апрель, 248 нче, 2020 ел, 27 май, 428 нче, 2022 ел, 31 март, 295 нче, 2022 ел, 29 сентябрь, 1045 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1447 нче, 2023 ел, 30 март, 380 нче, 2023 ел, 22 июнь, 741 нче, 2023 ел, 14 август, 980 нче, 2024 ел, 01 март, 109 нчы, 2024 ел, 25 июль, 592 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан

Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә, 5.52 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5.5$^{2}$. Башка бюджетара трансфертны тотырга рөхсәт ителә торган чаралар исемлеге:

социаль әһәмиятле объектларда төзелеш-монтаж һәм ремонт эшләре (авыл мәдәният йортлары, һәйкәлләр, күперләр);

авыл хуҗалыгы техникасы (трактор, печән чапкыч һ.б.) сатып алу;

юл-урам челтәрен ремонтлау һәм тротуарлар төзү;

ял итү урыннарын (парк, сквер, чишмә (агачлар кисү, үлән чабу, агач тамырларын казып чыгарудан башка)) төзекләндерү;

зиратларны төзекләндерү (коймалар, чүп баклары урнаштыру (аларны ремонтлау));

балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары сатып алу һәм аларны урнаштыру;

проект-тикшерү эшләрен башкару, сүүткәргеч челтәрләр һәм су җыю манаралары төзү, реконструкцияләү, ремонтлау һәм сынаулар уздыру;

эчәргә яраклы сүүткәргечләрне һәм су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарын билгеләү эшләрен башкару;

урам яктырткычларын урнаштыру һәм ремонтлау;

беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарын (мәйданчыкларын) булдыру (мондый бурыч башка затларга йөкләнгән булганда, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш).».

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин